Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР № VII**

Шумково авылы 9 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 өлешенең 19 пункты, “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шумково авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Карар, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәнең 4 бүлегендәге нигезләмәләрдән тыш, рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә, әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәнең 4 бүлеге нигезләмәләре 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково авылы, Центральный урамы, 4 йорт; адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Башлыгы Л.М. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советының
2021 елның
7 декабрендәге VII номерлы
карары беләнрасланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибен тәгаенли(алга таба – төзекләндерү өлкәсендә контроль).

1.2. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар (алга таба - контрольдә тотыла торган затлар) тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләрен (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре), социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен (алга таба шулай ук - мәҗбүри таләпләр) үтәүтөзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып тора.

1.3. Төзекләндерү өлкәсен тикшереп торуны (контрольне) Шумково авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет, җирлек) тормышка ашыра.

1.4. Башкарма комитетның төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлары – җирлек Башлыгы, шулай ук Башкарма комитет сәркатибе (алга таба-контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи затлар).Башкарма комитетның күрсәтелгән вазыйфаи затларының вазыйфаи бурычларына аларның вазыйфаи инструкциясе нигезендә төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә.

Тикшерүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга ия булалар һәм җавап тоталар.

1.5. Төзекләндерү, оештыру һәм профилактик чаралар, контроль чаралар үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.6. Башкарма комитет түбәндәгеләрне үз эченә алган төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота:

1) якындагы территорияләрне карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

2) элементларны һәм төзекләндерү объектларын тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән түбәндәге таләпләр:

– халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт, социаль хезмәт күрсәтү объектларына ирекле үтеп керүенә комачауламый торган киртәләрне урнаштыру буенча;

_торак булмаган биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасадларын, башка стеналарның, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның башка диварларын, шулай ук төзекләндерүнең һәм җәмәгать урыннарының башка элементларын карап тоту буенча;

– инженерлык корылмаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган махсус тамгалар, өсьязмалар эчтәлеге буенча;

– җир эшләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында һәм Төзекләндерү кагыйдәләрендә, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән җир эшләрен башкару тәртибенә туры китереп бирелә торган җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәтнамә нигезендә җир эшләрен гамәлгә ашыру;

– биналарга һәм аларга керү урыннарына ирекле үтеп керүне, шулай ук ишегалларына ирекле керү юлларын тәэмин итү, җәяүлеләр иминлеген һәм җәяүлеләрнең, шул исәптән инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең, җир эшләрен башкару чорында, иминлеген тәэмин итү буенча;

– транспорт чараларын газонда яисә башка яшелләндерелгән яисә рекреация территориясендә урнаштыруны булдырмау турында, анда төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә транспорт чараларын урнаштыру чикләнгән,шулай ук гомуми файдаланудагы территорияләрне файдалану, аларны эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү яки ремонтлау вакытында, йөк ташу яки төзелеш мәйданчыкларыннан чykканда транспорт чаралары белән пычрануга юл куелмау (тент яки каплау булмау аркасында);

3) кышкы чорда җирлек территориясен җыештыру буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән биналарның, корылмаларның түбәләрен, бозларын һәм боз сөңгеләрен чистарту буенча чаралар үткәрүне контрольдә тотуны да кертеп;

4) җәйге чорда җирлек территориясен җыештыру буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән карантин, агулы һәм чүп үләннәрен ачыклау, аларга каршы көрәш, аларны локальләштерү, бетерү буенча мәҗбүри таләпләрне дә кертеп;

5) махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгының өстәмә мәҗбүри таләпләре;

6) гомуми файдаланудагы территорияләрдә җир асты коммуникацияләрен салу, үзгәртеп кору, ремонтлау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

7) яшел утыртмаларны утырту, саклау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән агач һәм куакларны бетерү (кыру), кисү билеты һәм (яки) агач һәм куакларны күчереп утыртуга рөхсәтнамә нигезендә агач һәм куакларны күчереп утырту буенча мәҗбүри таләпләр,әгәр мондый документлар (кисүгә билет,

күчереп утыртуга рөхсәт) төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда бирелергә тиеш булса;

8) каты коммуналь калдыкларны өю буенча мәҗбүри таләпләр;

9) хайваннарны йөртү буенча мәҗбүри таләпләр һәм гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм төзекләндерү кагыйдәләрендә каралган башка территорияләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын көтүнең ярамавы турындагы таләпләр.

Башкарма комитет үз компетенцияләре чикләрендә тикшереп торырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшереп тора.

1.7. Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү элементлары дигәннән декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре аңлашыла,шул исәптән биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасадлары, кече архитектура формалары, стационар булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр.

Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү объектлары дигәннән төрле функциональ билгеләнештәге территорияләр аңлашыла, аларда төзекләндерү эшчәнлеге алып барыла, шул исәптән:

1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары),гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;

2) урам-юл челтәре элементлары (аллеялар, бульварлар, магистральләр, тыкрыклар, мәйданнар, юллар, проспектлар, тыкрыклар, разъездлар, төшү урыннары, трактлар, тупиклар, урамнар, шоссе);

3) ишегалды территорияләре;

4) балалар һәм спорт мәйданчыклары;

5) хайваннарны йөртү өчен мәйданчыклар;

6) парковкалар(парковка урыннары);

7) парклар,скверлар, башка яшел зоналар;

8) техник һәмсанитар-сакланузоналары;

Әлеге Нигезләмәдә киртәләүче җайланмалар дигәннән капкалар, кечкенә капкалар, шлагбаумнар аңлашыла, шул исәптән автоматик һәм декоратив киртәләр (коймалар).

1.8. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда хәвеф-хәтәрләрне бәяләү һәм идарә итү системасы кулланылмый.

## 2. Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар салу) хәвефлелеген профилактикалау

2.1. Башкарма комитет төзекләндерү өлкәсендә, шул исәптән профилактик чаралар үткәрү юлы белән, контрольне гамәлгә ашыра.

2.2. Профилактик чаралар тикшереп торучы затлар тарафыннан мәҗбүри

таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерергә сәләтле шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, контрольдә торучы затларга мәҗбүри таләпләрне, аларны үтәү ысулларын җиткерү максатларында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.3. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда зарар китерү куркынычын киметүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү контроль чараларын үткәрүгә карата өстенлекле юнәлеш булып тора.

2.4. Профилактик чаралар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү хәвефлелеген профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла, шулай ук зыян китерү куркынычын профилактикалау программасында каралмаган профилактик чаралар да үткәрелергә мөмкин.

Профилактик чаралар уздырганда контроль объектларының закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы яки мондый зыян китерүе ачыкланган очракта,төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат кичекмәстән контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен җирлек башлыгына бу хакта мәгълүмат юллый.

2.5. Башкарма комитет тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә түбәндәге профилактик чаралар үткәрелергә мөмкин:

1)мәгълүмат җиткерү (хәбәр итү);

2)консультация бирү.

2.6. Мәгълүмат бирү Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында (җирлек бүлеге) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - районның рәсми сайты) контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә тиешле белешмәләрне урнаштыру юлы белән мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла (махсус бүлеккә керү районның рәсми сайтының баш (төп) битеннән башкарылырга тиеш),шулай ук гаммәви мәгълүмат чараларында, контрольдә тотыла торган затларның шәхси кабинетлары аша дәүләт мәгълүмат системаларында (алар булган очракта) һәм башка рәвешләрдә.

Башкарма комитет районның рәсми сайтында контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 маддәсендәге 3 өлешендә каралган белешмәләрне урнаштырырга һәм аларга ярдәм итәргә бурычлы.

Башкарма комитет шулай ук контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр турында гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә халыкка хәбәр итәргә хокуклы.

2.7. Контрольдә торучы затларга консультация бирү телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итү яки профилактик чаралар, контроль чаралар үткәрү барышында контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.

Гражданнарны шәхсән кабул итү җирлек башлыгы һәм (яки) контрольдә

тотарга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелә.Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат районның рәсми сайтында контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла.

Консультация бирү телдән яки язма формада түбәндәге мәсьәләләр буенча башкарыла:

1) төзекләндерү өлкәсендә контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

3) контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

4) мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат алу, аларның үтәлешен бәяләү Башкарма комитет тарафыннан контроль чаралар кысаларында башкарыла.

Контрольдә торучы затларга телдән консультация бирү шулай ук гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.8. Язма рәвештә консультация контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) контрольдә торучы зат тарафыннан консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә җавап бирү турында язма гарызнамә тәкъдим ителү;

2) консультация бирү вакытында куелган сорауларга телдән җавап бирү мөмкин түгел;

3) куелган сорауларга җавап бирү мәгълүматны өстәмә соратып алуны таләп итә.

Консультация бирүне гамәлгә ашырганда контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи зат Россия Федерациясе законнары нигезендә керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген үтәргә тиеш.

Консультация бирү барышында конкрет контроль чарасына, контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына һәм (яки) гамәлләрен, контроль чарадагы башка катнашучыларның гамәлләрен бәяләгән мәгълүмат, шулай ук контроль чара кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынаулар нәтиҗәләрен үз эченә алган мәгълүмат бирелә алмый.

Консультация барышында консультация бирергә вәкаләтле вазыйфаи затка билгеле булган мәгълүмат, мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә торучы затны бәяләү максатыннан, Башкарма комитет тарафыннан файдаланыла алмый.

Контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан консультацияләрне исәпкә алу журналы алып барыла.

Башкарма комитетка контрольдә торучы затларның һәм аларның вәкилләренең бер типтагы биш һәм аннан күбрәк мөрәҗәгатьләре кергән очракта, консультация бирү Башкарма комитетның рәсми сайтында контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә урнаштыру, авыл җирлеге башлыгы яки вазыйфаи зат кул куйган язма аңлатма бирү юлы белән башкарыла.

3. Контроль чараларын һәм контроль гамәлләрен башкару

3.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда, Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелгән чаралар кысаларында контроль чараларының һәм контроль гамәлләренең түбәндәге төрләре үткәрелергә мөмкин:

1) инспекциявизиты(мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиешле документларны карау, сораштыру, документлар соратып алу, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү юлы белән);

2) рейд каравы (карау, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар соратып алу, инструменталь тикшерү, сынаулар, экспертиза);

3) документар тикшерү(язмача аңлатмалар алу, документларны соратып алу, экспертиза);

4) күчмә тикшерү (карау, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар соратып алу, инструменталь тикшерү, сынаулар, экспертиза);

5) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (төзекләндерү өлкәсендә контроль объектлары турында мәгълүматлар, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кирә торган мәгълүматлар җыю һәм анализлау юлы белән,алар мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контрольдә торучы затлар тарафыннан бирелә,шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган, “Интернет” челтәреннән, башка һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлардан, шулай ук фото - һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автомат режимында эшләүче техник чараларыннан файдаланып алынган мәгълүматлар;

6) күчмә тикшерү (карау, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып), сынау, экспертиза ярдәмендә).

3.2.Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү һәм күчмә тикшерү Башкарма комитет тарафыннан контрольдә торучы затлар белән бәйләнешсез үткәрелә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән контроль чаралары планнан тыш чаралар формасында үткәрелә.

Планнан тыш контроль чаралары бары тик прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына үткәрелергә мөмкин.

3.4. Контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлек итү белән үткәрелә торган контроль чаралары үткәрү өчен нигез булып тора:

1) гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре (гаризалары), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат килгәндә, башкарма комитетта закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү турында яисә зыян китерү куркынычы турында белешмәләр булу,шулай ук контроль чаралар үткәрү нәтиҗәсендә, үзара бәйләнешсез контроль чараларны да кертеп, мондый белешмәләрне алу, шул исәптән контрольдә тотылучы бүтән затларга карата үткәрелә торган контроль чараларны да кертеп;

2) Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль чаралары үткәрү турында йөкләмәсе;

3) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

4) мәҗбүри таләпләрне ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлану – контрольдә торучы зат тарафыннан үзенә бирелгән күрсәтмәдә каралган документлар һәм белешмәләр тапшырылмаган очракларда яисә тапшырылган документлар һәм мәгълүматлар нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү турындагы күрсәтмәнең үтәлеше турында нәтиҗә ясарга мөмкин булмаса.

3.5.Тикшерелә торган зат белән үзара хезмәттәшлектә уздырыла торган контроль чаралар Башкарма комитетның контроль чараны уздыру турындагы күрсәтмәсе нигезендә уздырыла.

3.6.Башкарма комитетның контроль чараны уздыру турында күрсәтмәсе закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү турындагы белешмәләр нигезендә кабул ителгән очрактамондый боерык төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затның контроль чарасын уздыру турында дәлилләнгән тәкъдиме нигезендә кабул ителә.

3.7. Контрольдә торучы затлар белән үзара бәйләнешсез үткәрелә торган контроль чаралары Башкарма комитетның эш планындагы биремнәр, җирлек башлыгы биреме нигезендә контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә,шул исәптән "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда да.

3.8. Гражданнарга, юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата контроль чаралары"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тикшереп торырга (контрольдә тотарга) вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә.

3.9. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Башкарма комитет түләүсез нигездә һәм (яисә) башка органнардан яки шушы документлар һәм (яисә) белешмәләр булган күрсәтелгән органнар карамагындагы оешмалардан, шул исәптән электрон рәвештә, мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) белешмәләрне ала. Күрсәтелгән документлар һәм (яисә) белешмәләр исемлеге, аларны тапшыру тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 19.04.2016 ел 724-р номерлы боерыгы белән расланган.Дәүләт контроле (күзәтчелек) органнарының, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган һәм алына торган документлар һәм (яисә) белешмәләр исемлеге нигезендә.Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2021 елның 6 мартындагы 338 номерлы карары белән расланган дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен, муниципаль контроль төрләрен

оештырганда һәм гамәлгә ашырганда кулланыла торган Кагыйдәләр.

3.10. Контрольдә торучы затлар булган индивидуаль эшкуар, граждан, тикшерү якынлашканда, Башкарма комитетка контроль чарасы үткәргәндә була алмавы турында мәгълүмат бирергә хокуклы.Шуңа бәйле рәвештә контроль чараны уздыру Башкарма комитет тарафыннан шәхси эшкуар, граждан өчен әлеге мөрәҗәгатькә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле срокка күчерелә (әмма 20 көннән дә артык түгел), бер үк вакытта түбәндәге шартларны үтәү кирә:

1) контрольдә тотылучы затның яисә аның вәкиленең булмавы, контрольлек чарасын үткәргәндә, төзеклəндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырырга, мәҗбүри таләпләрне үтәүне контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи зат бәяләвенә комачауламый, контрольдәге затка тиешле рәвештә контроль чарасын үткәрү турында хәбәр ителгән булса;

2) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүнең яисә фактта зыян китерүнең турыдан-туры янавы билгеләре булмау;

3) контрольдә тотылучы затның (контрольдә торучы затның авыруы, аның командировкасы һ.б.) булмау өчен җитди сәбәпләр бар.

3.11. Күчмә тикшерүне үткәрү вакыты 10 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Күчмә тикшерү барышында кече эшкуарлыкның бер субъектына карата багланышларның гомуми срогы кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән арта алмый.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы оешмага карата күчмә тикшерү үткәрү вакыты оешманың һәр филиалы, вәкиллеге, оешманың аерымланган структур бүлекчәсе яисә җитештерү объекты буенча аерым билгеләнә.

3.12. Күзәтүне башкарырга вәкаләтле вазыйфаи затлар һәм контроль гамәлләрне башкаруга җәлеп ителә торган затлар тарафыннан контроль чаралар үткәрүнең барлык очракларында мәҗбүри таләпләрне үтәүне (бозуны) дәлилләүләр өчен контроль чараны уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар үткәрә торган аудио- һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүлә,р фотосъемка кулланылырга мөмкин.Фотога төшерү, аудио- һәм видеога яздыру, геодезик һәм картометрик үлчәүләр һәм әлеге максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль чара нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм контроль чара кысаларында үткәрелә торган контроль гамәл нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагыла.

3.13. Контроль чара нәтиҗәләренә контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү ,мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү һәм (яки) аларны бозуларны туктату өчен шартлар тудыру, бозылган нигезләмәне торгызу, вәкаләтле органга яисә вазыйфаи затларга җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карау өчен мәгълүмат җибәрү һәм (яисә) Башкарма комитеты тарафыннан “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 маддәсендәге 2 өлешендә каралган чараларны куллану керә.

3.14. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чараны уздыру тәмамлангач, контроль чарасының акты төзелә.Мондый

чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нинди мәҗбүри таләп бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә.Ачыкланган бозуларны бетергән очракта, тикшерү чарасы тәмамланганнан соң актта аны бетерү факты күрсәтелә.Мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләре булган документлар, башка материаллар актка беркетелергә тиеш. Контроль чара уздырганда тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Актны рәсмиләштерү, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урынында башкарыла.

Прокуратура органнары тарафыннан килештерелгән контроль чарасы акты, аны рәсмиләштергәннән соң, контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестры аша, прокуратура органнарына җибәрелә.

3.15.Контроль чаралар турында мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чараларның Бердәм реестрында урнаштырыла.

3.16. Контрольдә тотылучы затларга контрольлек итәргә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан башкарылган эшләр һәм кабул ителә торган карарлар турында мәгълүмат бирүкүрсәтелгән гамәлләр һәм контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында карарлар турында мәгълүматларны урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла,шулай ук аларны контрольдә тотучы затларга җиткерү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт һәм муниципаль функцияләрне электрон формада үтәү өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктура аша,шул исәптән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы (функцияләр)” федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша (алга таба – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы) һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталы аша да.

Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаучы контрольдә торучы затка контрольлек итәргә вәкаләтле вазыйфаи затлар кылган гамәлләр, кабул ителә торган карарлар турында хәбәркәгазь йөрткечтә документлар юллау юлы белән, Башкарма комитет адресына кәгазьдә документлар алу кирәклеге турында хәбәр җибәрелгән очракта яисә Башкарма комитетта контрольдә тотыла торган затның электрон почтасы адресы турында белешмәләр булмаган очракта һәм аңа документларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы аша электрон рәвештә җибәрү мөмкинлеге булган очракта, документларын электрон рәвештә җибәрү юлы белән ирештерелә (затның бердәм идентификация һәм аутентификация системасында хисап язмасы булмаса яисә ул бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәү процедурасын узуны тәгәлләмәгән очракта).Күрсәтелгән граждан документларны кәгазь йөрткечтә җибәрергә хокуклы.

2023 елның 31 декабренә кадәр контрольдә тотыла торган затка күзәтүне, гамәлләрне һәм кабул ителә торган карарларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар турында мәгълүмат җиткерү, документлар һәм контрольдә тотыла торган затка белешмәләр җибәрү Башкарма комитет тарафыннан, шул исәптән,

электрон рәвештә контрольдә тотыла торган затка мәгълүмат бирү мөмкин булмаган очракта яисә контрольдә тотыла торган зат таләбе буенча, почта элемтәсеннән файдаланып, кәгазь йөрткечтә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.Контроль чара үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланмаган очракта, бу хакта белешмәләр контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына кертелә.Контрольлек итәргә вәкаләтле вазыйфаи зат мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча киңәшләр бирергә, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

3.18. Контроль чара үткәргәндә контрольлек итүче зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә Башкарма комитет (контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи зат) мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, бурычлы:

1) контрольдә тотыла торган затка контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең тиешле срокларын күрсәтеп һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне булдырмау чараларын башкару турында күрсәтмә бирергә;

2) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне булдырмау яисә зарар салуны туктату,гражданнарга, оешмаларга закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы булу һәм аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди үтемле ысул белән мәгълүмат җиткерү буенчаРоссия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән күрергә, тикшерү чарасын уздырганда төзекләндерү өлкәсендә контроль объектына ия булган һәм (яки) аннан файдаланучы граждан, оешма эшчәнлеге закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүгә турыдан-туры куркыныч тудыруы яки мондый зыян китерү ачыклану очрагында;

3) контроль чарасы барышында җинаять яисә административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрергә яисә тиешле вәкаләтләр булганда гаепле затларны законда билгеләнгән җаваплылыкка җәлеп итү чараларын күрергә;

4) мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерүне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтүне, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерергә мөмкин булганнарны булдырмый калуны тикшереп тору чараларын күрергә,күрсәтмәне үтәмәгәндә билгеләнгән срокларда, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәләрне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итеп, аның үтәлешен тәэмин итү чараларын күрергә;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү хәвефлелеген профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар уздыру буенча тәкъдимнәр бирү турындагы мәсьәләне карарга.

3.19. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда, тикшереп торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары,Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, оешмалар һәм

гражданнар белән билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлек итәләр.

Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль чара уздыру барышында закон таләпләрен бозу ачыкланган очракта, аның өчен Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган,контроль чара актында ачыкланган хокук бозу билгеләре булу турында мәгълүмат күрсәтелә.Тикшерүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар күрсәтелгән актның күчермәсен тиешле җаваплылыкка тартырга вәкаләтле хакимият органына юллый.

3.20. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаять бирүнең судка кадәрге тәртибе кулланылмый.

## 4. Төзекләндерү өлкәсендә контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре

4.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 маддәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2.Контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, төзекләндерү өлкәсендә контроль өчен индикатив күрсәткечләр авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә кушымта №1

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуның
ХӘВЕФЛЕЛЕК ИНДИКАТОРЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуның хәвефлелек индикаторлары булып тора:

1. Җирлекне төзекләндерү кагыйдәләрен бозу билгеләрен ачыклау.

2. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында чыгарылган законнары һәм башка норматив хокукый актлары беләнбилгеләнгән хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата мәҗбүри таләпләр бозылу билгеләрен ачыклау.

3. Дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, иҗтимагый берләшмәләрдән, индивидуаль эшкуарлардан, гражданнардан, гаммәви мәгълүмат чараларыннан гамәлләр (гамәл кылмау) турында белешмәләр алыну, алар закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы һәм (яисә) мәҗбүри таләпләр бозылу турында дәлилли.

4. Контроль чара йомгаклары буенча бирелгән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлүе турында мәгълүмат булмау.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә кушымта№ 2

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре,индикатив күрсәткечләре

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре:

| Төп күрсәткечләре | Максатчан кыйммәтләре (%) |
|---|---|
| Мәҗбүри таләпләрне бозуның ачыкланган саныннан бетерелгәннәренең өлеше | 70-80 |
| Контроль органының һәм (яисә) аның вазыйфаи затларының контроль чаралары үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата алынган шикаятьләрдән нигезле дип табылган шикаятьләр өлеше | 0 |
| Карарларның гомуми санынансуд тарафыннан юкка чыгарылган контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар өлеше | 0 |

2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре

1) муниципаль контроль органына кергән мәҗбүри таләпләрне бозу турында гражданнар һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләр саны (3);
2) муниципаль контроль органы тарафыннан планнан тыш тикшерү чаралары саны(3);
3) муниципаль контроль органы тарафыннан планнан тыш тикшерү чарасын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар саны(3);
4) мәҗбүри таләпләрне бозуның муниципаль контроль органы тарафыннан ачыкланган саны (3);
5) мәҗбүри таләпләрне бозуның бетерелгәннәре саны (3);
6) контроль чарасы актына карата кергән ризасызлыклар саны (0);
7) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында муниципаль контроль органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең саны (3).